**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКАИ ТАТАРСТАН**
пер. Школьный, д.7,
д. Тойгузино, Менделеевский район,
Республика Татарстан, 423646

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт,
Тойгуҗа авылы, Менделеев районы,
Татарстан Республикасы, 423646

Тел. (факс): (85549) 3-40-13
e-mail: Toyg.Men@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.05. 2023 ел № 6

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
"Тойгуҗа авыл җирлеге"
муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану
һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча
гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 статьясына, Тойгуҗа авыл җирлеге Уставына, Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башкарма комитеты Җәмәгать тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә ярашлы,
КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елның 30 июнендә 16 сәгать 00 минутта Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының административ бинасында Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү өчен түбәндәге составта комиссия төзергә:

Сафин Р. А. - Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе;

Кудрина Г. Р. – Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе урынбасары»;

Хәбибрахимов - Р.Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге депутаты (килешү буенча).

3. 2023 елның 30 маеннан 29 июненә кадәр Менделеевск муниципаль районы Тойгузинск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты материаллары экспозициясен Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт адресы буенча оештырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә (җибәрелә): 423646, Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Тойгуҗа авылы, Мәктәп тыкрыгы, 7 йорт (Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы исеменә).

5. Әлеге карарны Тойгуҗа авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга урнаштырып игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми

хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Тойгуҗа авыл җирлеге"бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

6. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге башлыгы Р.А. Сафин